

27 гыйнвар - Россиядә хәрби дан коне. Бу кон Ленинград шәһәре блокададан тулысынча азат ителгән (1944 ел). Изге жиребезне илбасарлардан саклап калган, анын иминлеге очен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнар рухы алдында баш иябез, аларнын батырлыгы һичкайчан онытылмас!
Ленинград блокадасы 871 кон дәвам иткән, халык ачлыктан иза чиккән. Һәрконне немецлар пулясыннан һәм vзәккә vткән ачлыктан, салкыннан йоз менләгән кешенен гомере озелгән. 1944 елнын 27 январе шәһәрнен тулысынча азат ителгән коне дип исәпләнелә. Бу конне Ленинградта бәйрәм салюты атыла. Илебез белән бергә, бу конгә багышлап, торле чаралар Мордовиядә дә vтте. Беренче чиратта, барлык мәктәпләрдә «Блокада ипие» дигән акцияләр, дәресләр, укучыларга халык батырлыгы турында сойләvче истәлекле чаралар иде.      Кечкенә генә кыз буларак бомбалар шартлавын кvргән, ачлыкны, vзәккә vтә торган салкынны һәм гомумән 1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышынын ин куркыныч сәхифәләреннән берсе булган Ленинград блокадасы куркынычын кичергән Адилә Үмәр кызы Кичемасованын хатирәләрен «Темников хәбәрләре» бастырган.
Тагы бу ачы коннәрнен шахиты, бvген Тархан авылында гомер итvче Сания Рәхим кызы Агеева белән Аксел урта мәктәбе укучылары, «Блокада кондәлекләре» дигән батырлык дәресе алдыннан, очраштылар; озак иттереп Сания Рәхим кызы язмышынын Ленинград блокадасында vткәргән коннәре турында белделәр. Тархан китапханәчеләре дә Сания Рәхим кызын блокадалы Ленинград истәлеге коне белән котладылар. Бvген Ленинград шәһәре камалышынын тугыз йозгә якын конен кvз алдына китерve кыен. Букадәр кахәр коннәрне киләчәктә балалар кvрмәсен, ботен доньяда тынычлык булсын иде!